58

# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Хезмәткә түләүнең минималь күләме турында**

1 статья. 1997 елның 1 маеннан хезмәткә түләүнең минималь күләмен айга 250 000 сум итеп билгеләргә.

2 статья. Салымнар, җыемнар, эшсезлек буенча пособиеләр, дәүләт пошлинасы, штраф, зыянны каплау һәм законнар нигезендә гамәлгә ашырылучы башка түләүләрне хезмәт хакының Россия Федерациясендә гамәлдә булган минималь күләменнән чыгып башкарырга.

Гражданнарның түләем керемен булган ташламаларны һәм өстәмәләрне исәпкә алып санарга.

3 статья. Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына әлеге Законда каралган чараларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслау тәртибен һәм чыганакларын билгеләргә.

4 статья. 1995 елның 13 сентябрендәге "Хезмәткә түләүнең минималь күләме турында" Татарстан Республикасы Законы көчен югалткан, дип санарга.

5 статья. Әлеге Законны 1997 елның 1 маеннан гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1997 елның 24 апреле
N1149